КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# КИБЕТТӘ ФОТОГА ТӨШЕРҮНЕ ТЫЮ ЗАКОНГА КАРШЫ КИЛМИМЕ?

**«Дус кызым туйга чакырды һәм, әлбәттә инде, минем алга нәрсә кияргә дигән сорау килеп басты. Кыйммәтле бутикка барып, үземә шундый тантаналы вакыйгага туры килә торган күлмәк сайларга булдым. Нәтиҗәдә, ике купшы күлмәк таптым, әмма кайсына тукталырга да белмәдем. Шунлыктан аларның икесен дә фотога төшереп, кайсын сайлап алырга икәнлеге турында үз киңәшен бирсен өчен, фотоларны дустыма җибәрергә карар кылдым. Әмма шулвакыт яныма сатучы килеп басты һәм ишек янындагы игъланга (анда «Фото– һәм видеога төшерү тыела!» дип язылган иде) күрсәтеп, моны эшләргә ярамый, дип белдерде. Мондый игълан законга каршы килмиме?**

**Ирина К.»**



РФ Конституциясенең 29нчы маддәсендә һәр гражданинның «мәгълүматны теләсә нинди законлы юл белән эзләү, алу, тапшыру, җитештерү һәм тапшыруга» хокукы күрсәтелгән. Моннан тыш, 2006 елның 27 июнендә кабул ителгән 149нчы федераль законның («Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында») 7нче маддәсендә «бөтен кешегә дә ачык мәгълүмат» дигән төшенчә бар. Аңа файдалану чикләнмәгән бөтен кешегә дә билгеле һәм башка төрле мәгълүматлар керә.

Товар турындагы мәгълүмат, шул исәптән аның бәяләр күрсәткече дә, закон нигезендә алардан файдалану чикләнгән дәүләт һәм коммерция сере түгел. Шулай булгач, кибеттә сатыла торган товар турындагы мәгълүматлар бөтен кешегә дә ачык. Алардан, гамәлдәге закон нигезендә, үз ихтыяры буенча теләсә кем файдалана ала.

**Шуны истә тотарга кирәк:** мәгълүматларны ачу бурычы яки алардан файдалануны чикләүгә юл куймау башка федераль законнар белән билгеләнгән икән, алар коммерция сере була алмый. Шул рәвешле, фото– һәм видеога төшерүне тыю да гамәлдәге законнарга туры килми.

СОРАУ-ҖАВАП

# Намаз вакытында көлеп җибәрсәң тәһарәт бозыламы?

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН җавап бирә.**

ҖАВАП: Әлеге сорауга җавап биргәнче, «көлү» төшенчәсе белән бәйле кайбер күренешләргә ачыклык кертергә кирәк.

Көлүне, намазга йөгынты ясау күзлегеннән караганда, шартлы рәвештә өч төргә бүләргә мөмкин.

Янында утырган күршең ишетерлек дәрәҗәдә кычкырып көлү. Көлү тавышы янында утырган күршеңә ишетелми, көлгәнеңне бары үзең генә тоясың. Йөз, ирен, күзнең торышы үзгәрү, әмма, асылда, бу көлү түгел. Әлеге күренеш елмаю дип атала, бу очракта бернинди дә тавыш чыкмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре намазда кычкырып көлү намазны да, тәһарәтне дә боза дигән бердәм фикердә тора. Намаз үтәлгән булып саналсын өчен, яңадан тәһарәт алырга һәм көлү сәбәпле бозылган намазны кабаттан укырга кирәк.

Көлүнең икенче категориясе бары намазны гына боза, тәһарәт бозылмый.

Намаз укыганда елмаю намазны да, тәһарәтне дә бозмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең хаклы булуын раслаучы хәдисне китерик. Җабир бин Абдуллядан тапшырылган: «Кем дә булса намазда көлсә, намазын кабаттан укысын, әмма тәһарәтне кабат алуга ихтыяҗ юк» (Сахих Бохари, Китабүл вуду, 1/46)(1).

Хәдистә телгә алынган «көлү» сүзе гомуми мәгънәгә ия һәм ул нинди дә булса сыйфат белән бирелмәгән. Димәк, бу хәдистә янында утырган кеше ишетерлек дәрәҗәдә кычкырып көлү әйтелгән дип аңларга кирәкми.

Шулай ук Ибн Хумам «Фәтхүл Кадир» китабында болай дигән: «Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне да бозуы хакында хәбәр итүче хәдисләр Пәйгамбәрдән берәзлексез иснад (тапшыручылар чылбыры) белән дә, мөрсәл (табигыйн белән Пәйгамбәр арасындагы сәхабәне телгә алмыйча) чылбыры ярдәмендә дә килә. Хәдис фәне белән шөгыльләнүче галимнәр мөрсәл чылбыры белән Пәйгамбәрдән тапшырылган хәдис ышанычлы тапшыручыдан килсә, аны дөрес дип саныйлар. Әлеге темага мөрсәл хәдисне Абел Алия, Хәсән Басри һәм Ибраһим ән-Нахаи тапшыра».

Зәйд бин Халидтән тапшырыла, ул болай дигән: «Бервакыт Пәйгамбәр үзенең сәхабәләре белән намаз укыган һәм шул вакытта бер сукыр кеше коега төшеп киткән, бу күренештән берничә сәхабә көлгән. Пәйгамбәр намазны тәгалләгач, борылган һәм аларга әйткән: кайсыгыз да булса көлгән булса, тәһарәтен яңартсын һәм намазын кабаттан укысын» («Сүнән Даракутни», 623)(6).

Хәдистән аңлашылганча, Пәйгамбәр аларны ишеткән, димәк, көлү тавышы ишетелгән. Һәм бу хәдисне бары шул мәгънәдә аңларга кирәк. Ә Җәбир бин Абдуллядан тапшырылган хәдис аны бары тулыландыру гына булып тора.

Нәтиҗә ясап Имам Мөхәммәд ибн Әл-Хәсән Әш-Шәйбаниның сүзләрен китерәсе килә: «Әгәр дә хәдисләр булмаса, кыяс (аналогия буенча фикер йөртү) нигезендә, барысы да мәлики мәзһәбе галимнәре әйткәнчә булыр иде (ягъни кеше намаз укыганда көлсә тәһарәт бозылмас иде). Әмма кыяс мөмкин түгел, чөнки Пәйгамбәрдән килгән хәдисләр бар, һәм моңа охшаш барлык очракларда да (аерым алынган темага хәдис булганда), без бары хәдистә әйтелгәнне генә эшләргә тиешбез» (Имам Мөхәммәд, «Әл Хуҗа», 1/204)(7).

*ТР мөселманнары Диния нәзарәте матбугат хезмәте*

чаян
юмор бите
chayan-journal.ru Реклама 16+

***

– Мәгариф министрлары имтиханнарны 4 сыйныфтан ук кертергә тәкъдим итә...

– Нишләп 4тән генә??? Әйдәгез, беренче сыйныфка кергәндә үк имтихан тапшырсыннар! Бирә алмасаң – бетте-китте, бар, әнә, эшкә кер!

***

– Җәйгә бераз акча җыярга теләгән идем.

– Нишләп, әллә хәзер җәй дә түләүлеме?

***

Мин урамда шаурма сатып алмыйм. Өйдә үзем ясыйм. Чын шаурма кебек килеп чыга: бер-ике тапкыр агуландым да хәттә.

***

Хатын-кыз кызыктыргыч кредит кебек: уңайлы шартлар, матур реклама, документлардан да паспорт кына җитә, тик аннан соң гомереңә буе бурычлы булып яшисең.



Николай Воронцов рәсеме

***

– Доктор миндә башка авыру табыгыз әле! Монысына акчам җитми.

***

Акулалар кешеләргә сирәгрәк һөҗүм итә башлаган... Кешеләр тәмле түгел... Силикон да ботокс!

***

– Сез нишләп табиб булырга карар кылдыгыз?

– Сайлау мөмкинлеге зур түгел иде, мин бит медицина институтын тәмамладым...

***

Ә бит элек интернет, социаль челтәрләр булмаганда синең дивана икәнеңне өйдәгеләр генә белә иде.

***

– Сәлам, нәрсәләр эшләп йөрисең?

– Мин – акционер.

– Акцияләр сатып аласыңмы?

– Юк, акцияләр булганда сатып алам.

***

Күп кенә сәясәтчеләр һәм эшкуарларның гомердә дә туздырып бетерә алмаслык акча җыйганын күргәч, үлгәч тә тормыш дәвам итәчәгенә шикләнми башлыйсың.

Тәмле атна

# ЭРЕМЧЕКЛЕ «СИННАБОН»

**«Синнабон» – рулет кебек ясалган йомшак күмәч. Аңа төрле эчлек салып пешерергә була. Эченә – эремчек, ә өстенә каймаклы крем салынган «синнабон» рецепты тәкъдим итәбез.**

Гөлүзә ВАСИЛОВА



Г.Василова фотосы

**Камыр ясау өчен кирәк:** *350 грамм он, 5 грамм коры чүпрә, 100 грамм сөт, 50 грамм шикәр комы, 50 грамм маргарин (яки атланмай, үсемлек мае), 70 грамм каймак, 3,5 грамм тоз.*

**Эчлек өчен кирәк:** *500 грамм эремчек, 1 йомырка, 100 грамм шикәр комы.*

Крем өчен кирәк: 200 грамм кибет каймагы, 1-2 аш кашыгы шикәр комы.

Камыр басарга һәм җылыга кабартырга куярга. Күтәрелгәч, баскалап янә кабартырга. Аннары камыр җәяргә һәм өстенә эремчекле эчлекне ягарга, рулет итеп төрергә.

Рулетны кисәкләргә кисеп чыгарга һәм әлеге кисәкләрне майланган табага ара калдырып тезәргә. Табада бер-берсенә кушылганчы кабартырга. Аннары мичкә куярга.

Күмәчләр пешеп җитеп әле кайнар чагында өстенә мул итеп крем агызырга. Кремга бер йомырка да өстәргә мөмкин. Ул вакытта «синнабон»нарны сүндерелгән, әмма кайнар мичтә 10 минутка якын тотарга кирәк.

**АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ**
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Татар–информ» мәгълүмат агентлыгында әзерләнде.

Генераль директор – Шамил Мөхәммәт улы Садыйков.
Баш редактор – Рәмис Нурмөхәммәт улы Латыйпов.
Җаваплы редактор – Лилия Гаделшина.
Дизайн–верстка – Светлана Щеглова.
Корректор – Раис Габдуллин.

Тел.: (843) 222–09–83 (1304; 1414)
Редакция һәм нәшир адресы:
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2нче йорт.
Эл.адрес: info@tatar–inform.tatar
Реклама хезмәте телефоны: (843) 570–31–07

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә Федераль күзәтчелек хезмәтенең (РОСКОМНАДЗОР) Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2014 елның 9 гыйнварында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы: ПИ №ТУ16–01140
Басмага бирү вакыты: 19 февраль 2020, график буенча – 24.00, гамәлдә – 24.00
Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ

Нәшир адресы:
420097, Казан ш., Академия ур., 2
**Басылу урыны:**
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы.,
Казан ш., Декабристлар ур., 2
Тираж –46 120 экз.
**Гомуми тираж: 67 726 экз.**

Редакция фикере автор фикере белән туры килмәскә мөмкин. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарының дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

© Язмаларны күчереп бастыру фәкать редакция рөхсәте белән генә башкарылырга тиеш. Газета атна саен чыга. Бәясе ирекле.

*«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла*
16+